СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ**
09 октябрь, 2024 ел

**КАРАР**
№ 449

**Биектау муниципаль районы Советының 2022 елның 09 декабрендәге 241 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы 1 өлешенең 20 пункты, 3 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча 2021 елның 17 июнендәге гавами тыңлаулар беркетмәләрен һәм 2024 елның 28 августындагы гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының 2022 елның 09 декабрендәге 241 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына, аны кушымта нигезендә түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Генераль планын территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасы рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә

органнары белән үзара хезмәттәшлеге, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов